**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының кайбер указларын үз көчен югалткан дип тану хакында**

1. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында хокук саклау эшчәнлеген тәэмин итү чаралары турында» 1991 елның 31 июлендәге ПУ-62 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт аппараты органнарында һәм учреждениеләрендә сәяси партияләрнең оештыру структуралары эшчәнлеген, шулай ук сәяси максатларны күздә тоткан массакүләм иҗтимагый хәрәкәтләрне туктату турында» 1991 елның 31 августындагы ПУ-107 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы территориясендә иҗтимагый хәрби берләшмәләр һәм кораллы формированиеләр төзүне һәм аларның эшчәнлеген тыю турында» 1991 елның 17 октябрендәге ПУ-167 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Эчке эшләр министрлыгының хезмәт белән төзәтү эшләре һәм социаль реабилитацияләү хезмәте эшчәнлеген камилләштерү чаралары турында» 1991 елның 30 ноябрендәге ПУ-224 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында юридик затларның уйлап эшләнгән банкротлыгын кисәтү чаралары турында» 2001 елның 1 августындагы ПУ-655 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы студентлары һәм мәктәп укучылары арасында программалаштыру буенча ачык команда турнирында җиңгән өчен Татарстан Республикасы Президенты бүләкләрен гамәлгә кую турында» 2010 елның 31 мартындагы ПУ-182 номерлы Указы.

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2023 ел, 23 ноябрь
№ 801